***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА

**БИРЕМНӘРЕ**

(2025-2026 нчы уку елы)

**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 180 минут**
**Максималь балл – 70**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләрнең санын билгеләгез. **(2 балл)**

*Аю кыш буе йоклый, “йокым туйды” дими.* (Мәкаль)

а) 2
ә) 3
б) 4
в) 5

2. Җөмләдәге кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

*Урманга утын ташылмый, коега су салынмый.* (Мәкаль)

а) урманга
ә) ташылмый
б) коега
в) салынмый

3. Фразеологизмның синонимын билгеләгез. **(2 балл)**

***күздә тоту***

а) телдә тоту
ә) уйда тоту
б) колакта тоту
в) каршыда тоту

4. Архаизмны билгеләгез. **(2 балл)**

а) фейк
ә) редукция
б) алпавыт
в) сәгадәт

5. Мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) эшлә-мә-дек
ә) эшлә-мә-де-к
б) эш-лә-мә-де-к
в) эш-лә-мә-дек

6. Күләм-чама рәвешен билгеләгез. **(2 балл)**

а) тиз
ә) шактый
б) салмак
в) бушка

7. Җөмләдәге фигыльләрнең төркемчәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүре баласын тотарга өйрәтсә, сарык баласын качарга өйрәтә.* (Мәкаль)

а) инфинитив, хикәя фигыль, инфинитив, хикәя фигыль
ә) хәл фигыль, шарт фигыль, хәл фигыль, боерык фигыль
б) инфинитив, шарт фигыль, инфинитив, хикәя фигыль
в) хәл фигыль, шарт фигыль, хәл фигыль, хикәя фигыль

8. Сүзтезмәнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

***күн диван***

а) сыйфатлы исем сүзтезмә
ә) исемле исем сүзтезмә
б) исемле сыйфат сүзтезмә
в) сыйфатлы сыйфат сүзтезмә

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Бүрегә* ***кунакка*** *барсаң, этеңне калдырма.* (Мәкаль)

а) тәмамлык
ә) урын хәле
б) максат хәле
в) сәбәп хәле

10. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Юан булса да, ялгыз агачтан өй булмас.* (Мәкаль)

а) синтетик иярчен тәмамлык җөмлә
ә) синтетик иярчен аергыч җөмлә
б) синтетик иярчен шарт җөмлә
в) синтетик иярчен кире җөмлә

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Тавышның сөйләмдәге төрлечә хәрәкәте _____________ дип атала. Рус-европа телләреннән кергән алынма сүзләрне шул телдәгечә язу _____________ принцип була. _____________ – диалектларны өйрәнә торган фән. Кушымчалар сүз ясагыч һәм _____________ ясагыч дигән ике төргә бүленәләр. Рәвеш гади, чагыштыру һәм _____________ дәрәҗәсендә була ала. Ике яки берничә гади җөмләдән торган җөмлә _____________ җөмлә дип атала.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Парлы сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

| | |
|---|---|
| ________-тәртип | ________-нәсәп |
| ________-ыру | ________-нәсихәт |

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(10 балл)**

Родина подобна огромному дереву.___________________________________

Но всякое дерево имеет корни._______________________________________

Корни питают дерево и связывают его с землёй.________________________

___________________________________________________________________

Корни – это то, чем мы жили вчера, год назад, сто, тысячу лет назад. ______

___________________________________________________________________

Это наша история.__________________________________________________

Человеку нужно знать свои корни.____________________________________

Тогда вода и воздух, которым мы дышим, будет целебен и вкусен. *(В.Песков)*

___________________________________________________________________

___________________________________________________________________

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

ТУГАН ЯК

Җитәмени безнең туган якка:
Җәен – яңгыр, кышын кар исен
Күкрәгеңә сулап, биек таудан
Ил киңлеген сөенеп карыйсың!
Бик күңелле тәңкә кар яуганда,
Кунып эри битләр очында...
Кулга тотсаң энҗе бөртекләрен,
Көмеш тамчы кала учыңда.

(*Нур Гайсин*)

2.1. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз, басымнарын билгеләгез. **(3 балл)** _______________________________________________

2.2. ***Яуганда*** сүзен иҗекләргә таркатып языгыз, иҗек калыпларын билгеләгез. **(2 балл)** _________________________________________________________

2.3. Шигырьдә кулланылган антоним сүзләрне парлап языгыз. **(2 балл)**

___________________________________________________________________

2.4. Икенче дүртьюллыктагы ясалма сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

__________________________________________________________________

2.5. Икенче дүртьюллыктагы затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(2 балл)** ______________________________________________________________

2.6. Бирелгән җөмләгә синтаксик анализ ясагыз: баш кисәкләрнең астына сызыгыз, компонент чикләрен билгеләгез, схема сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. **(4 балл)**

***Кулга тотсаң энҗе бөртекләрен,***
***Көмеш тамчы кала учыңда.***

_________________________________________________________________

3. «***Туган ягымның матурлыгы***» дигән темага 10-12 җөмләдән торган инша языгыз. **(15 балл)**